ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 апрель, 2022 ел № 14/12

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү ташламаларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 53 пункты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2022 елның 1 апреленә кадәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, түбәндәге эшчәнлек алып барган, «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затлар, оешмалар, шәхси эшмәкәрләрне аренда түләвеннән азат итү рәвешендәге ташламаны билгеләргә:

1) балаларның интеллектуаль, мәдәни, сәнгать-эстетик, спорт үсеше;

2) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә.

2. Әлеге Карарның 1 пунктында билгеләнгән ташлама Башкарма комитет тарафыннан расланган тәртиптә 2023 елның 1 апреленә кадәр бирелә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ